ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында

Россия Федерациясе Конституциясенең 104 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасын хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына, шулай ук Татарстан Республикасыннан сайланган Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына мөрәҗәгать итәргә.

3. Күрсәтелгән федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан рәсми вәкил итеп Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты И.И. Гыйльметдиновны билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

БЕРКЕТМӘ БУЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре,
2019 елның 14 феврале
№ 2723-V ДС